

# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№2 Октябрь 2023 ел*

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА 2023 УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ



**Матурлыкка гашыйк укытучым**

Мин мәктәбебездәге талантлы, оста, шаян, алтын куллы укытучыларыбызның берсе – Төхфәтуллина Фәрдия Римхәт кызы турында язарга телим. Ул – технология , рәсем, жыр дәресләрен укыта. Аның кабинетына кергәч, Фәрдия апа ясаган эшләнмәләргә карап таң, каласың. Искиткеч матур бу әйберләрнең кул астында булган дисклар, банкалар, шешәләр, төрле тукымалардан, җепләрдән эшләнгәненә ышанып та булмый.

Укытучыбыз бу эшкә укучыларын бик теләп өйрәтә. Аннан күреп, технология дәресләре өчен дип, кирәкмәс пластик, картон һәм башка әйберләр җыябыз. Шулай итеп, остазыбыз үзенең һөнәре аша табигатьне сакларга, мөмкин булган әйберләрне кабат кулланырга өйрәтә.

Иң беренче кыяр кем бакчасында өлгерә? Иң эре җиләкләр кем бакчасында үсә? Ел әйләнәсе кемнең тәрәзә төпләрен чәчәккә күмелгән гөлләр бизи? Әлбәттә, безнең яраткан укытучыбыз - Фәрдия апа Төхфәтуллина турында бу сүзләр. Нинди генә чәчәкләр үстерми ул. Кайсын ничек тәрбияләргә кирәклеген аннан башка оста белүче юк.

Фәрдия Римхәт кызы безне тәмле әйберләр пешерергә дә өйрәтә. Төрле күргәзмәләр дә оештыра, үткәрелгән һәр чарада биергә, җырларга кирәк булганда, киңәшләрен бирә, гомумән, Фәрдия апабыз алтын куллы мөгаллим.

**6 нчы сыйныф укучысы Халитова Илвинә**




**Укытучы**

Һөнәрләр күп, кем булсаң да
Табиб, эшче, тукучы.
Тик онытма бер нәрсәне:
Юл күрсәтә – укытучы.

**Вәлиев Ранель, 2 нче сыйныф укучысы**

**Һөнәрле кеше бай була**

Һөнәрле кеше бай була диләр. Күп һөнәрләр остасы булган күршебез - Гыйлаҗев Гаяз абый матур, зур гаиләнең өлкән кешесе. Балта остасы буларак ул күп җиһазлар эшләгән , матур беседкалар төзегән, зур йортын салган, ә инде табигатьне яратып искиткеч бакча утырткан. Гаяз абый 1948 нче елны Күәм авылында туган. Тормыш иптәше Зәйтүнә апай белән өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Инде 50 ел бергә матур итеп гомер кичерәләр. Лаеклы ялда булса да, ул гел хезмәттә, хәрәкәттә. Яратып башкарган тагын бер шөгыле бар, Гаяз абый тал чыбыгыннан бишекләр һәм кәрҗиннәр үрә. Кешеләргә аның хезмәте бик ошый . Тал чыбыгын эшкәртеп ул, күп сабырлык куеп чын сәнгать әсәрләрен тудыра . Беренче бишеген ул бик яшьли, 13 яшендә үк үрә. Аннан соң эшләнмәләрен ул тагын да камил итеп эшләгән. Барлыгы ике йөздән артык бишек үргән. Тал агачын дөрес итеп сайлау мөһим икән, агач туенып үсәргә, яфраклары үзе коелып бетсә яхшы. Тал чыбыкларының кайберләрен төпкә, кайберләрен янын үрү өчен баганалык өчен сайлап алам, ди. Агачны кайнар суда пешекләп эшкәртә. Аннан суытып, бүлмә температурасында тоту кирәк.Тал агачы бөгелүчән, сыгылмалы, безнең якларда бик күп итеп үсә. Теләгән кеше декоратив читәннәр дә эшли ала. Һөнәре турында бик кызыклы итеп сөйли күрше абый. Оныкларым бишекне үрә белә ди оста. Бик сирәк һөнәр иясе булган, күршебез Гаяз абыйга рәхмәт әйтүчеләр бик күп. Чөнки ул үргән бишекләр матур да, уңайлы да, алар останың күңел җылысы салынып эшләнгән.

**9 нчы сыйныф укучысы Ганиева Дилә**

**Әлифбам**

Көз җитте тышта,
Сары яфраклар оча.
Ә мин барам мәктәпкә
Әлифбам бар сумкада.
Укыйбыз инде сүзләр,
Аннан язабыз саннар.
Кушабыз да алабыз,
Шулай белем алабыз.

**1 нче сыйныф укучысы Садриева Ралия**

**Көз**

Минә көз килде:
Салкынча җилле
Агачларда яфраклар
Саргайды инде

Уңыш җыелды
Аккошлар китте
Матур көз ае
Октябрь җитте

**2 нче сыйныф укучысы Халитова Иркә**

## Без коррупциягә каршы!




Без, 5 нче сыйныф укучылары, Мирхазианова Алия, Садриева Айсинә һәм Шамонова Камилла “Бел һәм юл куйма!” антикоррупцион юнәлештәге республика конкурсының мәктәп этабында катнаштык. Дүшәмбедән башлап һәр көнне дәресләрдән соң калып, конкурсның шартлары буенча “Плакат” номинациясенә туры китереп, мин “Коррупциягә юк!” темасына, сыйныфташым Айсинә “Таратмагыз!” темасына плакатлар ясадык. Ә сыйныфташым Камилла “Видеоролик” номинациясенә “Сайлау синнән тора!” дигән темага видеоролик эшләп җибәрде. Хәзер без эшләребезнең нәтиҗәсен көтәбез.

**Мирхазианова Алия, 5 нче сыйныф укучысы**



## Күңел кояшым –әбием, дәү әнием

Әбиләр- тормышыбыздагы ямь бирүче иң шәфкатьле, иң газиз кешеләребез. Шушы көзге кояшлы да, яңгырлы да көздә әбиләребез кебек җылы бәйрәм булу – үзе бер сөенеч бит. Шуңа күрә дә октябрь ае әбиләребез, дәү әниләребез бәйрәме булу белән аерылып тора. Һәр елны 1 октябрьда Өлкәннәр көне билгеләп үтелә.
Өлкәннәр көне уңаеннан сыйныф белән бергәләп, әбиләребез, дәү әниләребезне кунакка чакырдык. Аларны котлап, концерт номурлары, дәртле биюләр, моңлы җырлар әзерләдек. Шигапов Камил баянда “Уфтанма” көен сузды. Сыйныф җитәкчебез Гөлнара Зөлкарь кызы әбиләребезгә бүләкләр тапшырды.

Әбиләребез үзләре турында сөйләделәр һәм матур теләкләр теләделәр. Бәйрәм бик күңелле үтте. Соңыннан укучылар һәм килгән кунаклар чәй өстәле артында әңгәмәләрен дәвам иттеләр.

Без үзебезнең мәктәптә шундый матур традицияләр булу белән горурланабыз.

**Шакирова Камилә, 6 нчы сыйныф укучысы**

## Бәйрәм көн

Беркөн безнең мәктәптә
Бик күркәм бәйрәм булды.
Өлкәннәрне хөрмәтләп
Балалар концерт куйды

Килгән әби-бабайлар
Концерт карап куанды.
"Булдырдыгыз,балалар",- дип
Өйләренә таралды.

**4 нче сыйныф укучысы Юсупов Рөстәм**




## Хәрәкәттә – бәрәкәт

Укуның беренче чиреге бетеп килә. Ә без нинди генә чараларда катнашмадык. Хәтта узебез бик куп чара оештырдык. Иң беренче, 7 нче сентябрь көнне “Движение Первых”акциясе буенча "Автобус туры" нда проект яклап кайттык. Икенчесе, экологик турнир "Чистые игры" Казан шәһәрендә узды, безнен сыйныфтан 4 укучы Ноксинский урманны жыештырып кайттык. Ә хәзерге вакытта ул турнирның онлайн этабында, "Другое дело" платформасында экологиягә кагылышлы эшләр башкарабыз. Өченче чара, "Посвящение в Движение Первых" узды. Безнен сыйныфтан 3 кыз, һәм 9 нчы сыйныфтан 1 укучы «Движение Первых» акциясендщ узләренең 1 нче зур адымнарын атладылар. Дуртенче чара, "Встреча с единомышленниками" безнең мәктәптә узды. Без анда Хәлил Шәйхайнур улы белән очраштык. Һәм җиһангирлар турында бик куп мәгълумат алдык. Мәктәп туры олимпиадалары да башланды. Әйдәгез тырышып укыйк. Хәрәкәттә-бәрәкәт!

**Сибагатова Ильвинә, 8 нче сыйныф**

## Халык сынамышлары

**-октябрьдә** каен яфраклары коелып бетмәсә, кар соң ятар.
**- октябрьдә** кәннәр коры икән, кыш әле тиз генә житмәс.
**- октябрьдә** – соры болытлар түбән йөзә икән, көн бозылыр.
**- октябрьдә** иртән кар очса, кыш суык килер.
**-октябрьдә** аякка иярерлек пычрак икән, 4 атнадан чын кыш килер.

## Безнең юбилярлар

– Балалар язучысы, Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты **Җәүдәт Дәрзаман**га 70 яшь (1945).
-Язучы **Мәгъсүм Насыйбуллин**ның тууына 90 ел (1925-2009).
- Шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе **Заһидә Бурнашева**ның (Гыйффәт туташ) тууына 120 ел (1895–1977).
-Тел галиме, филология фәннәре кандидаты **Искәндәр Абдуллин**ның тууына
80 ел (1935–1992).

## Хәерле юл
## Юл билгеләрен өйрәнәбез

